«Раслыйм»
Сәләт оешмасы проектлары
житәкчесе
_________ Әдип Әлмир
«_1_» _март_ 2021 ел

**Х Ачык Флүс Латыйфи исемендәге**
**«Сәләткә нур булган йолдызлар» әдәби конкурсы**

## НИГЕЗЛӘМӘСЕ

### 1. Конкурсны оештыручылар

Флүс Латыйфи исемендәге «Сәләткә нур булган йолдызлар» Х Ачык әдәби конкурсы (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы «Сәләт» иҗтимагый фонды, «Сәләт» Клубы тарафыннан оештырыла.

### 2. Конкурсның максаты һәм бурычлары

Конкурсның максаты – талантлы яшь авторларның татар әдәбияты өлкәсендәге иҗади потенциалын үстерүдә булышлык күрсәтү.

Конкурс үз алдына түбәндәге бурычларны куя һәм гамәлгә ашыра:

– әдәбият өлкәсендә сәләтле балаларны һәм яшьләрне барлау, аларга иҗади яктан камилләшүдә, үсүдә ярдәм күрсәтү;

– балаларда һәм яшьләрдә эстетик зәвык һәм әдәби мәдәнияткә мәхәббәт тәрбияләү;

– сәләтле яшь язучыларның игътибарын хәзерге заман татар әдәбиятына һәм татар халкының рухи мирасына юнәлдерү;

– талантлы язучы һәм Сәләт оешмасы катнашучыларының остазы танылган татар язучысы Флүс Латыйфиның исемен Сәләт мохитендә яңгырату һәм яшәтү;

– сәләтле яшьләрне Сәләт оешмасы проектларына җәлеп итү.

### 3. Конкурсның номинацияләре

– шигърият,

– чәчмә әсәр,

– балалар әдәбияты,

– драматургия,

– публицистика.

**4. Конкурсның казыйлар шурасы**

4.1 Конкурсның казыйлар шурасына Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзалары, танылган шагыйрьләр һәм прозаиклар, күренекле журналистлар һәм мәдәният эшлеклеләре керә.

4.2 Конкурсның нәтиҗәләре баш казый имзалаган протокол белән раслана.

**5. Конкурсның катнашучылары**

5.1 Конкурста 11 яшьтән алып 22 яшькә кадәр булган сәләтле мәктәп балалары һәм белем бирү оешмалары студентлары катнаша ала.

5.2 Конкурс түбәндәге яшь категорияләре арасында үткәрелә:

– 11-14 яшь;

– 15-18 яшь;

– 19-22 яшь.

**6. Конкурста катнашучыларның эшләренә карата куелган шартлар**

6.1 Конкурска иҗади эшләр түбәндәге күләмдә кабул ителә:

– шигърият – 3 язмадан күбрәк , 6 язмадан  азрак булырга тиеш;

– чәчмә әсәр – 1, яки 2 язма булырга тиеш;

– балалар әдәбияты – 1, яки 2 язма булырга тиеш;

– драматургия – 1, яки 2 язма булырга тиеш;

– публицистика – 2 язмадан күбрәк, 4 язмадан азрак булырга тиеш.

6.2 Конкурска  татар телендәге иҗади эшләр кабул ителә.

6.3 Иҗади эшләр өчен авторлар үзләре җавап бирә.

6.4 Конкурска кабул ителгән иҗади эшләр кире кайтарылмый.

6.5 Конкурста катнашу өчен гаризалар Сәләт оешмасының рәсми сайтында www.selet.biz кабул итеп алына.

6.6 Конкурста катнашучы берничә номинациядә көч сынарга теләсә, аңа тиешле санда гариза тутырырга кирәк.

6.7 Конкурс эшләре selet.nur@gmail.com адресы белән электрон почтага кабул итеп алына.

6.7.1 Хатның темасы түбәндәгечә күрсәтелә: Номинация – катнашучының фамилиясе (тулысынча), исеме һәм этисенең исеме (инициаллары).

*Үрнәк:* Шигърият – Вәлиуллина А.Р., 18 яшь

6.8 Конкурс эшләре түбәндәге шартларга туры китереп языла:

– шрифт: Times New Roman;

– шрифтның зурлыгы: 14;

– юлара интервал: 1,5;

– әгәр иҗади эш шигырь формасында булса, текст битнең сул ягы буенча тигезләнә; әгәр иҗади эш проза формасында булса, текст бит киңлеге буенча тигезләнә;

– язманың исеме уртада ярымкалын шрифт белән күрсәтелә.

6.9 Конкурс эшенең титул бите түбәндәге пунктлардан гыйбарәт (Кушымта №1 кара):

– катнашучының исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча), телефон номеры;

– номинация;

– катнашучының тулы яше;

– катнашучының уку урыны, сыйныфы (курсы);

– җитәкченең исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча) һәм вазыйфасы, телефон номеры.

6.10 Оештыру комитеты конкурска кабул ителгән эшләрне төрле матбугат чараларында бастырырга хокуклы.

6.11 Оештыру эшләренә түләү 300 сум тәшкил итә. Түләү конкурсның финал көнендә регистрация вакытында кабул ителәчәк.

**7. Конкурсның үткәрелү вакыты һәм урыны**

«Сәләткә нур булган йолдызлар» конкурсы берничә этапта үткәрелә:

– 3-нче март, 2021 ел – 1-нче апрель, 2021 ел – гаризаларны кабул итү этабы;

– 2-нче апрель, 2021 ел – 3-нче апрель, 2021 ел – иҗади эшләрне конкурска сайлап алу этабы;
– 4-нче апрель, 2021 ел – 11-нче апрель, 2021 ел – конкурска кабул ителгән эшләрнең казыйлар шурасы тарафыннан бәяләнү этабы;
– 16-нчы апрель 2021 ел – конкурсның финалы Казанда Сәләт Йортында (Островский ур., 23-нче йорт) уздырылачак.

**Конкурсны оештыру комитетының контактлары**

Конкурсны оештыру комитеты Сәләт Йортында (Казан, Островский ур., 23-нче йорт) урнашкан. Белешмәләр өчен телефон: +7(843) 292-16-00.

Конкурсның җитәкчесе: Вәлиуллина Айгөл Равил кызы, +79274119797.

E-mail: selet.nur@gmail.com.

Сәләт оешмасының рәсми сайты: www.selet.biz.

«ВКонтакте» социаль челтәрендә Сәләт оешмасының рәсми төркеме: https://vk.com/selet.official.

Кушымта 1.

1. Катнашучының исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча), телефон номеры;
2. Номинация;
3. Катнашучының тулы яше;
4. Катнашучының уку урыны, сыйныфы (курсы);
5. Җитәкченең исем-фамилиясе, әтисенең исеме (тулысынча), вазыйфасы һәм телефон номеры.